## Булыйк һәрчак хәер-догада

Әнкәйләрнең күңеле бигрәк йомшак,

Ачулана белми беркайчан.

Балаларын канат асларына,

Күңеле аның җыя һәркайчан.

Әнкәйләрнең күркәм холыклары,

Бер җирдә юк уйлап карасаң.

Әнкәйләрнең хәер-догасыннан,

Аермасын ходай беркайчан.

Юлга чыксаң хәер-фатыйхасын,

Теләп кала безгә әнкәйләр.

Кулын куеп кашы өсләренә,

Балаларым, сез бит кошкайлар.

Ана күңеле һәрчак балада бит,

Безнең күңел булсын анада.

Далаларда озак йөрсәк тә без,

Булыйк һәрчак хәер-догада.

*Мехаматнур Нәҗметдинов, 2021 ел, август*